Алга, белем иленә!


# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

16 нчы гыйнвар, 2015 нче ел
№ 2



## Әлеге санда:



Тарих сәхифәләре ( 2нче бит)




Сәламәт тәндә– сәламәт акыл
( 3 нче бит)



Илһам канатында ( 4 нче бит)

**Ява карлар, яңа карлар…**

**Ява карлар, яңа карлар –**
**Кышның ак гөлләре.**
**Якты булсын, ап-ак булсын**
**Илемнең көннәре.**
**Ишетелеп торсын җирдә**
**Балалар көлгәне.**

**Р.Миңнуллин**

**Кышкы бураннар.**

Кыш килеп җиткәч,
Була бураннар.
Кар белән тула
Бөтен урамнар.

Кышыбызның бураннары
Борыннарны чеметә.
Кайвакытта йомшак җиле
Битләрне сыйпап үтә.

Кыш бит салкын булса да,
Кояш нурларын сибә.
Минем тәрәз төпләремә
Кошкайларым да килә.

**Азалия Гарипова,**
**4 нче сыйныф укучысы.**



# Тарих сәхифәләрендә

## Фатих Кәрим— солдат –шагыйрь



**Фатих Кәрим** (1909 елның 9 гыйнварында Башкортстан Республикасы Бишбүләк районының Ает авылында туган — 1945 елның 19 февралендә Кенигсберг тирәләрендә вафат булган) – татар шигъриятенең сәнгатьчә үсешен яңа, югары дәрәҗәгә күтәреп, гражданлык каһарманлыгы һәм шигъри батырлык күрсәтеп, милләтебезнең һәм аның сүз сәнгатенең йөз аклыгы булырлык мирас калдырып һәлак булган шагыйрь.

### Ант

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә — балам. Син әнкәсе
аның,
Балабызны тотып ант итәм.

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан
җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм…

**Фатих Кәрим**

***Еллар миннән үзенең соравын***
***Баганага терәп сорады.***
***Еллар минем күңел сафлыгын***
***Утка-суга салып сынады.***

### Сөйләр сүзләр бик күп алар

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул:
Күп яшәргә теләсәң,
Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

**Фатих Кәрим**



**Уфа дәүләт «Нур» татар театры Фатих Кәримнең фаҗигале язмышын гәүдәләндергән “Ясмин гөле” әсәрен сәхнәләштерде. Рәсемнәрдә спектакльдән күренешләр.**





**Материалны 7 нче Г сыйныфы укучылары Ильвина Садреева һәм Алсу Әхмәдуллина әзерләделәр**



## Балет

Балет - сәхнәләштерелгән бию сәнгате. Сәхнә балетында сюжет ята. Балет Италиядә барлыкка килгән. Безгә ул 1673 нче елда килеп керә. Мин аны телевизордан, интернеттан һәм Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрына барып карыйм. Танылган биючеләр: Анастасия Волочкова, Алонсо Алисия, Алла Евгеньевна, Николай Цискаридзе.

Әлеге төр биюне башкару өчен күп тырышлык, тренировкалар кирәк.

**Диана Зәйнулллина,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**



## Нәфис гимнастика

Минем яраткан спорт төрем – нәфис гимнасттика, чөнки ул спорт кына түгел, ә матурлык, грация, җитезлек һәм түземлелек. Гимнасткалар ритмны сизәргә һәм шуңа туры килә торган хәрәкәтләр ясарга тиешләр.

Әлеге спорт төре физик яктан чыныккан һәм эстетик яктан бай булган кешеләрне тәрбияли.

**Алсу Хасанова,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**



## Минем яраткан спорт төре

Тимераякта фигуралы шуу – кышкы олимпиада уеннарына керә. Әлеге спорт төре 1924 нче елда кышкы олимпиада уеннарының программасына кертелгән. Ул берничә төргә бүленә: парлы яки парсыз шуу. Беренче тапкыр медальләрне Ирина Родина, Александр Зайцев ала. Шулай ук Аделина Сотникова, Евгений Плющенко кебек исемнәр барыбызга да таныш.

Фигуралы шуу бик матур спорт төре. Мин тимераякта шуарга яратам.

**Дарья Кузягина, 5 нче Г сыйныфы укучысы**

## Озынлыкка сикерү

Озынлыкка сикерү буенча ярыш төре олимпиада уеннарына ир-атлар өчен 1896 нчы елдан, ә хатын-кызлар өчен 1948 нче елдан кертелгән.

Дөнья рекордларына Татьяна Щелканова, Татьяна Котова, Татьяна Лебедеваның нәтиҗәләре кертелгән.

**Дарья Андрякова,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**



# Илһам канатында



Яңа ел тылсымлы, күңелле бәйрәмнәрнең берсе. Яңа елда безне  яңа бәхет, яңа очрашулар көтә. Шуңа күрә һәрбер кеше теләкләр тели, Кыш бабайдан нәрсәдер өмет итеп яши башлый.

Кыш бабай!

Исәнме, Кыш бабай!  Сиңа хат язучы Ксюша исемле кыз. Мин сине Яңа ел бәйрәменә көтәм. Сине шатландырыр өчен мин тырышып укыйм, әти-әниемнең сүзләрен тыңлыйм, олы кешеләрне хөрмәт итәм. Кичә генә өйдә матур чыршы куйдык.

Яңа елда барлык кешеләргә сәламәтлек, шатлык теләп калам.

**Ксения Николаева,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**

Исәнме, Кыш бабай!

Тиздән Яңа ел килә. Кыш бабай, мин сиңа сәламәтлек, шатлык телим. Син хыялларны чынга ашырырга булышасың, шуңа мин сине яратам.

Яңа елга мин синннән матур һәм яхшы бүләкләр көтеп калам. Ә иң мөһиме минем әти-әнием, туганнарым, дсларым исән-сау булсыннар иде.

Кыш бабай, син һәрвакыт шат күңелле, акыллы, сәламәт бул. Мин сине көтәм.

**Снежанна Семенова,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**



Исәнме, Кыш бабай!

Хәзер урамда ак сакалын туздырып салкын кыш та күптән аяк басты. Ә инде тиздән Яңа ел бәйрәме дә килеп җитәр. Мин сине үзебезгә кунакка чакырасым килгән иде.

Бу елда мин үземне тәртипле тоттым. Әниләргә дә булыштым, яхшы билгеләргә генә укырга тырыштым. Менә кичә генә без өйдә чыршы куеп, аны матур итеп бизәдек. Хәзер бүлмәдә чыршының тәмле хуш исе сөендереп тора.

Яңа елда барлык кешеләрнең дә исән-сау яшәүләрен телим. Син дә, Кыш бабай, авырма.

Яңа 2015 нче ел белән!

**Ксения Федорова,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**

Исәнме, Кыш бабай!

Синең хәлләрең ничек? Бәйрәмгә әзерләнеп ятасыңдыр, әйеме?

Кадерле Кыш бабай, миңа Яңа ел бәйрәменә песи баласын бүләк ит әле.

**Дамир Нәбиуллин,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**





### Ә мин җәйне сагынам...

Урамда үзенең зәмһәрир сыуклары белән кыш күптән аяк баскан. Ләкин шулай да җәйге көннәрне һаман сагынам. Җәй көне мин “Сталкер” лагерында булдым. Анда яңа дуслар белән таныштым. Төрле уеннар уйнадык. Әлеге лагерь турында кечкенә генә шигырь дә яздым:

“Сталкер” лагерында булдым,
Яңа дуслар белән таныштым.
Бу мизгелләр белән куандым,
Һәр көн саен хатлар алыштым.

**Зәринә Хәмитҗанова,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**

### Күңелле кыш килде

Урамда әкияти кышкы көн. Әле кичә генә кап-кара булган җир ап-ак кар белән капланган. Бөтен дөньяда аклык, сафлык хөкем сөрә. Аяк астында яңа яуган кар шыгыр-шыгыр килә. Кар бөртекләрендә аклык та, сафлык та, шатлык та бар. Кар яуганда, күзләрем генә түгел, күңелем дә иркәләнә. Ап-ак бәскә төренгән агачларны кем матур димәс? Саф, салкын һавасын сулап, күкрәгеңә шифа һәм дәва аласың. Керфекләреңә, чәчеңә, иреннәреңә күбәләк кар килеп куна. Бу карлар барысы да синеке. Җилне бишек итеп, кар бөртекләре тирбәтә. Кар ява... Яусын әйдә, шатлыклар чиксез булсын!

**Алсу Әхмәдуллина,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

### Минем мәктәбем

Мин Казан шәһәренең 78 нче мәктәбендә укыйм. Безнең мәктәбебез зур һәм якты.

Мәктәп – ул уку һәм укытучылар гына түгел, монда минем дусларым бар. Һәр көнне очрашканда сыйныфташларым белән яңалыклар турында сөйләшәбез, рәсемнәр ясыйбыз, җырлар җырлыйбыз.

Безнең укытучыларыбыз уку өчен уңайлы шартлар тудыралар, без дә аларга ярдәм итәбез: сыйныф бүлмәсен тәртиптә, чисталыкта тотабыз.

Кайвакыт укытучылар дәресләрдә таләпчән, усал булып тоелалар, ләкин, шуңа да карамастан, без аларны яратабыз һәм хөрмәт итәбез. Алар укучыларны белемле, тәртипле итеп тәрбияләргә тырышалар. Укытучыларыбыз игътибарлы, киң күңелле һәм акыллы. Аларга төрле сораулар яудыра алабыз.

Мин үземнең мәктәбемне бик яратам. Мәктәпне бетереп чыккач та, аны сагынып искә алырмын дип уйлыйм.

**Алсу Хәсәнова,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**

# Илһам канатында



«Тиздән Яңа ел»
**Дарина Груздева,**
**1 нче сыйныфы укучысы**

### Әнием

Ходай биргән әниләргә
Чиксез бетмәс сабырлык.
Көч тә биргән, биргән куәт тә
Изгелегенә дә таң калырлык..

Рәхмәт, энкәй, бүләк иттең
Якты дөньяның ямен.
Яшьлегеңне кызганмыйча,
Белергә тормыш тәмен..

Авырганда керфек какмадың.
Төннәр буе мине сакладың.
Кысып җылы кочагыңа
Җил давылдан якладың.

**Дарья Соколова,**
**5 нче М сыйныфы укучысы**

***

Төнлә буран ишек шакый,
Салкын җиле белән куркыта.
Тәрәзәгә шакып яный,
Кышкы сукмакларны тузгыта.

**Ризган Заһидуллин,**
**5 нче Г сыйныфы укучысы**



«Кар Бабай чана шуа»
**Наил Гарипов,**
**1 нче Б сыйныфы укучысы**



«Ак кар ява»
**Елизавета Житлухина,**
**1 нче Б сыйныфы укучысы**

# Илһам канатында

## Мөселман солдат

Дәү бабам – горурлыгым!
Ул – сугыш каһарманы!
Сугыш юлын, герман җирен,
Гизгән бөтен дөньяны.

Лагерьларда газап күргән,
Кичкән фашист михнәтен.
Безнең өчен тәнен биргән.
Күрерме ил хөрмәтен?

Бер мәл яралы килеш
Дога укыган чакта,
Немец солдаты күргән дә,
Гаҗәпкә калган шунда.

Үлем җазасын көтсә дә,
Шундук мөселман солдат,
Сугыш тәмамланган чакта,
Ителә шулчак азат.

Туган ягына кайтса да,
Шатлык белән аралап,
Янә газаплар кичерә,
Үз намусларын аклап.

Ышанмыйлар безнекеләр:
“Син сатлыкҗандыр!” –
диләр.
Үз тугрылыгын дәлилләп
дип,

Нишлисең бит, канун шундый.
Баштан гына сыйпамый.
Концлагерьдан котылсаң да,
Ул каһарман булалмый.

***Тиздән Бек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәчәкбез***

Үткән көннәр, узган гомер,
Гафу да үтенделәр.
Әмма сәламәтлек кенә
Сатып алынмый диләр.

Бары алтмыш тулып кына
Күрде ул бу дөньяны.
Дәү бабам – горурлыгым!
Ул – сугыш каһарманы!



**Эмиль Инсафутдинов,**
**6 нчы Е-М сыйныфы укучысы**

# Мәктәп хәбәрләре

## Безнең җиңүләребез

31 нче октябрь, 12 нче һәм 13 нче ноябрь көннәрендә “Җиңү поэзиясе” исемле район шигырь конкурсы үтте. Безнең укучыларыбыз сәнгатьле сөйләүләре, сәхнәдә үзләрен тотышлары, уңышлы чыгышлары белән соклandырдылар.

Һәр мәктәп көчле, әйбәт итеп әзерләнеп килгән иде. Берәүләр язучыларның шигырьләрен сөйләсәләр, ә икеченчеләре үзләре язган шигырьләрен тәкъдим иттеләр. Жюрилар исә һәрбер чыгышны игътибар белән тыңлап, бәяләп бардылар.

Безнең мәктәптән 4 нче, 7 нче, 10 нчы сыйныф укучылары актив катнашып, алдынгы урыннарга лаек булдылар.





Конкурсның җиңүчеләре:

1 нче урында Әхмәдуллина Алсу (7 нче Г сыйныфы укучысы);

2 нче урында Мотыйгуллина Гөлназ ( 7 нче М сыйныфы укучысы),

2 нче урында Валеева Диләрә (10 нчы А сыйныфы укучысы);

3 нче урында Бикчәнтәева Регина (10 нчы А сыйныфы укучысы),

3 нче урында Гомәрова Энже ( 4 нче Б сыйныфы укучысы).

Тәбрик итәбез! Зур уңышлар телибез!

**Гөлмирә Батталова,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

## Очрашу

“Сабантуй” журналы хезмәткәрләре белән очрашулар безнең мәктәпнең традициясенә әверелде. 11 нче ноябрь көнне Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, баш мөхәррир урынбасары Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлова белән очрашу үткәрелде. Анда журналның 90 еллык юбилее, тарихы һәм киләчәге турында сүз алып барылды, чыгышлар ясалды. Балалар басылып чыккан шигырьләрен, редакциягә җибәреләчәк мәкалә һәм экиятләрен укыдылар, үзләрен борчыган, кызыксындырган сорауларын да бирделәр.

Кичә ахырында викторина сорауларына җавап биргән укучыларга бүләк итеп журналлар таратылды.

Бу очрашу безнең күңелдә якты истәлек булып калды.





**Алсу Әхмәдуллина,**
**7 нче Г сыйныфы укучысы**

# Сыйныфтантыш эшчәнлек ярминкәләре

Тормышка һәр яктан әзерлекле, югары әдәп, әхлак сыйфатларына ия булган шәхесне тәрбияләү хәзерге көндә дә актуаль мәсьәләләрнең берсе.

Сыйныфтантыш чаралар, фәнни эзләнү эшләренә презентацияләр төзү, төрле кул эшләре белән мавыгу балаларның күзаллавын киңәйтә.





Безнең мәктәптә «Сәламәт туклану» түгәрәге эшләп килә. Түгәрәк балаларның сәламәтлек турында күзаллауларын киңәйтү, дөрес туклану белән сәламәтлекнең бәйләнештә булуын аңларга булышу, үзеңнең сәламәтлегең өчен кайгыртучанлык һәм аны саклый белү хисләрен тәрбияләү максатларын алга куя.

Мәктәбебездә «Мәктәбем минем» газетасы белән берлектә рус телендә дә чыгып килгән газеталар бар: «Кадетский вестник», «Новостное ассорти». Алар да үзләренең нәфис басмаларында мәктәп тормышын, танылган шәхесләр турында мәгълүматлар урнаштыралар.





«Оста куллар» түгәрәгендә балалар чигәләр, фанер тактада төрле проектлар эшлиләр , төсле кәгазьдән әйберләр ясыйлар.



# Эш беткәч, уйнарга ярый



**Мәкальләр**

**Күп укысаң, күп белерсең.**

***

**Белем бәхетле итә.**

***



**Белемлекнең чиге юк.**

***

**Белем һәр куркынычны җиңә.**

***

**Китап-белем чишмәсе.**

***

**Кояш җирне яктырта, уку кешене.**

***

**Галим белсә сорый,надан белми дә,сорамый да.**

## Котлыйбыз!



*Яңа ел белән!*

Җир өстенә аклык-пакьлек алып килгән Яңа ел бәйрәме белән котлыйбыз! Киләсе елның 365 көне дә бәхет-шатлык кына китерсен. Аткан таңнарның барысы да алсу, тормыш юлларызда шатлыклы очрашу-лар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын! Яңа ел җилләре саулыкларыгызга ныклык, өегезгә иминлек, җаннарыгызга нур, күңелләрегезгә якты илаһи рәхәтлек алып килсен.

**Мөхәррирләр:** А. Әхмәдуллина, Г.Батталова, С. Семенова, И.Садреева, Э. Гибадуллина, И.Салахов, Р. Идрисов, А. Мәрданова.
**Консультант:** Л.И. Исмаилова

*Мәктәбем минем*

**Безнең адресыбыз:** ТР Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс: 268– 58-61
E– mail: https://edu.tatar.ru/priv/school78
**Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:**
https://edu.tatar.ru/priv/school78/page813169.htm
**Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:**
lyutsiya_906@mail.ru